ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.4,
с. Старое Русское Маматкозино, 422589

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 4 нче йорт,
Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, 422589

Тел.: (84379) 33-6-31, факс: (84379) 33-6-31.

16.11.2020 № 2

На №__________ от__________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында
халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 16нчы ноябрендә узган «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында «Мазарки» чишмәсен төзекләндерү, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше, тавыш бирүдә 83 кеше катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 83 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, 450 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Иске

Рус Мәмәтхуҗасы авылында «Мазарки» чишмәсен төзекләндерү, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләрен танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында халык җыенының нәтиҗәләрен Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Никитушкин